| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЯЛКЫНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИ-<br>ПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБ-<br>ЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЯЛКЫН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ — д.Ялкын — КАРАР

21.05.2020 — №122

Үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсендәге 1 пунктының 3 пунктчасының «б» абзацынүтәү йөзеннән «Татарстан Республикасы ныңаерым закон актларына коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә вазыйфаи затларның аерым категорияләренең катнашу тәртибен камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 07 маендагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә

Ялкын авылҗирлеге Советы караркылды:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының авыл җирлеге Советының 2017 елның 25 сентябрендәге 50 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен бушлай рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмә хакында» карары;

-Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары

составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 20 июнендәге 101номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулайук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстем дә калдырам.

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципальрайонының
Ялкын авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.В.Гущина